КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 28 февраль г.Казань № 141

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү турында» 2023 ел, 25 декабрь, 1682 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү турында» 2023 ел, 25 декабрь, 1682 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 16 апрель, 256 нчы; 2024 ел, 10 декабрь, 1125 нче; 2025 ел, 16 май, 331 нче; 2025 ел, 29 декабрь, 1184 нче карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыкларына:

мохтаҗ гражданнарга җирле бюджетлар акчасы исәбеннән өстәмә социаль ярдәм чаралары билгеләүне;

социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә бәйле мәсьәләләрне карау өчен ведомствоара комиссияләр төзүне;

«Татарстан Республикасының Эшмәкәрлеккә ярдәм фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясенә индивидуаль эшмәкәрлек эшчәнлеген оештыруга социаль контрактлар төзегән махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына булышлык күрсәтеп торуны (эшмәкәрлеккә ярдәм итүнең республика һәм федераль чаралар буенча консультация, мәгълүмат бирү, укыту һәм проектларны алып бару, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү һәм аларга ярдәм итү буенча төбәк программаларын гамәлгә ашыруга бәйле хезмәтләрнең башка төрләрен күрсәтү) оештыруны.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәдә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Нигезләмә «Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – 178-ФЗ номерлы Федераль закон) $8^1$ статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән гражданнарга, авыр тормыш ситуациясен җиңеп чыгуга актив гамәлләр кылу өчен аларга стимул бирү максатларында, һәм 178-ФЗ номерлы Федераль законның $8^1$ статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән гражданнарга, индивидуаль эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруга актив гамәлләр кылу өчен аларга стимул бирү максатларында, Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү тәртибе һәм шартларын билгели.»;

3 пунктта татар текстында «тормышта авыр хәлдә калган гражданнарга» сүзләреннән соң «, гражданнарга – «Ветераннар турында» 1995 елның 12 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – 5-ФЗ номерлы Федераль закон) 3 статьясындагы 1 пунктының 1 пунктчасында күрсәтелгән һәм махсус хәрби операциядә катнашкан хәрби хәрәкәтләр ветераннарына һәм 5-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 пунктының $1^1$, $2^2$ – $2^6$ пунктчаларында күрсәтелгән хәрби хәрәкәтләр ветераннарына (алга таба – махсус хәрби операциядә катнашучылар), һәм 178-ФЗ Федераль законның $8^2$ статьясы 1 өлешендә күрсәтелгән башка затларга» сүзләрен өстәргә;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Гаиләнең җан башына уртача керемен, ялгыз яшәүче гражданның керемен исәпләү, аз керемле гаилә составын билгеләү «Гаиләнең җан башына туры килә торган керемен һәм ялгыз яшәүче гражданның керемен исәпкә алу тәртибе турында, аларны аз керемлеләр дип тану һәм аларга дәүләт социаль ярдәме күрсәтү өчен» 2003 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 44-ФЗ номерлы Федераль закон) һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Гаиләнең җан башына туры килә торган керемен исәпләгәндә исәпкә алына торган керем төрләренең һәм ялгыз яшәүче гражданның аларга дәүләт социаль ярдәме күрсәтү өчен керемнәре исемлеге турында» 2003 елның 20 августындагы 512 номерлы карары нигезендә исәпләнә.

Әлеге Нигезләмәнең 10 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән чараны гамәлгә ашыру максатларында 178-ФЗ номерлы Федераль законның $8^1$ статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән гражданнарга җан башына уртача гаилә (ялгыз яшәүче граждан) керемен исәпләү башкарылмый.

Аз керемле гаилә әгъзасы Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган граждан булса, аз керемле гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар гаиләләренә социаль ярдәмнең кайбер чараларын, шулай ук дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү үзенчәлекләре турында» 2022 елның 29 октябрендәге 1933 номерлы карарының 1 пунктын исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

44-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы буенча социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү хокукын билгеләгәндә һәм гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләгәндә исәпкә алына торган гаилә составына түбәндәгеләр керми:

а) тулысынча дәүләт тәэминатында булган затлар (гариза бирүчедән, шулай ук аның опекасындагы яисә попечительлегендәге балалардан, җайлаштырылган төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда белем алучы һәм яшәүче балалардан тыш);

б) хәрби хезмәткә чакырылу буенча хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләр, шулай ук хәрби һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирү хәрби мәгариф оешмаларында белем алучы һәм хәрби хезмәт узу турында контракт төземәгән хәрби хезмәткәрләр;

в) иректән мәхрүм итү рәвешендәге җәзаны үтәгән затлар;

г) суд карары буенча мәҗбүри дәвалануда булган затлар;

д) сак астына алу рәвешендә чикләү чарасы кулланылган затлар;

е) хәбәрсез югалган яки үлгән дип игълан ителгән затлар;

ж) эзләнә торган затлар;

з) гариза бирүченең балигъ булмаган балалары, гариза бирүче опекасындагы (попечительлектәге) балалар, гариза бирүченең гомуми белем бирү оешмасында, һөнәри белем бирү оешмасында яисә югары белем бирү мәгариф оешмасының көндезге бүлегендә белем алучы, никахлашкан 23 яшькә кадәрге балалары.»;

5 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, билгеләү турында гариза (алга таба – билгеләү турында гариза), социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүне туктату турында гариза (алга таба – туктату турында гариза), шулай ук социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен китереп бирү ысулын үзгәртү турында гариза (алга таба – китереп бирү ысулын үзгәртү турында гариза) граждан тарафыннан яшәү урыны яки тору урыны буенча территориаль социаль яклау органына шәхсән (аз керемле ялгыз яшәүче гражданнар өчен) яки үз гаиләсе һәм әлеге Нигезләмәнең 9 пунктында күрсәтелгән гражданнарның башка категорияләре исеменнән (алга таба – гариза бирүче) тапшырыла:

бишенче абзацта:

«социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме», «(алга таба – билгеләү турында гариза)» сүзләрен төшереп калдырырга;

«(алга таба – билгеләү турында гариза),» сүзләреннән соң «туктату турында гариза» сүзләрен өстәргә;

алтынчы абзацта «социаль контрактсыз дәүләт социаль ярдәмен билгеләү турында гариза,» сүзләреннән соң «туктату турында гариза,» сүзләрен өстәргә»;

җиденче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Территориаль социаль яклау органында теркәлгән билгеләү турында гариза, туктату турында гариза, шулай ук китереп бирү ысулын үзгәртү турында гариза булганда шул ук гариза бирүче тарафыннан кабат бирелгән билгеләү турында гариза, туктату турындәа гариза, шулай ук китереп бирү ысулын үзгәртү турында гариза кабул ителми.

Территориаль социаль яклау органында гариза бирүченең гаилә әгъзасы

тарафыннан тапшырылган һәм теркәлгән билгеләү турында гариза булганда билгеләү турында гариза кабул ителми.

Туктау турында гариза, шулай ук китереп бирү ысулын үзгәртү турында гариза социаль контракт нигезендә дәүләт ярдәмен билгеләгән территориаль социаль яклау органына бирелә.»;

6 пунктта:

беренче абзацта «гариза бирүче тарафыннан» сүзләреннән соң «әлеге Нигезләмәнең 19 пунктында билгеләнгән срок эчендә» сүзләрен өстәргә, «(барлыкка килгән конкрет тормыш хәленә карап)» сүзләреннән соң «, шул исәптән дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр бердәм порталын файдаланып» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Индивидуаль эшмәкәрлек эшчәнлеген башкару чараларын гамәлгә ашыруга билгеләү турында гариза белән мөрәҗәгать иткәндә, гариза бирүче бизнес-план, шәхси ярдәмче хуҗалыкны алып бару өчен чыгымнар сметасын тапшыра.

Бизнес-планда түбәндәге бүлекләр булырга тиеш:

гражданның резюмесы (белем турында мәгълүматларны (мәгариф оешмасы исеме, уку чоры һәм алынган белгечлек (квалификация, һөнәр) кертеп); сайланган эшчәнлек өлкәсендә эш тәҗрибәсе турында мәгълүматлар (оешма исеме, биләгән вазифа, эш чоры); тиешле эшчәнлек төрләренә лицензияләр, патентлар, сертификатлар, авторлык хокуклары һ.б. булу турында мәгълүматлар);

проект һәм маркетинг планы тасвирламасы;

оештыру планы (персоналның штат структурасы, квалификация таләпләре һәм эш графигы тасвирламасы);

җитештерү планы (товарлар (эшләр, хезмәтләр) булдыруның технологик эзлеклелеге тасвирламасы);

финанс планы һәм проектның нәтиҗәлелек күрсәткечләре;

рисклар һәм аларны минимальләштерү чаралары тасвирламасы.»;

9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Түбәндәгеләр социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәменнән файдалану хокукына ия:

а) үзләренә бәйле булмаган сәбәпләр аркасында җан башына уртача кереме «Россия Федерациясендә яшәү минимумы турында» 1997 елның 24 октябрендәге 134-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасында билгеләнгән халыкның җан башына яшәү минимумы күләменнән түбәнрәк булган, 178-ФЗ номерлы Федераль законның $8^1$ статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән аз керемле гаиләләр, аз керемле ялгыз яшәүче гражданнар һәм гражданнарның башка категорияләре – аларга авыр тормыш хәлен җиңеп чыгу буенча актив гамәлләр кылуга стимул бирү максатларында;

б) хәрби хезмәттән (хезмәттән, эштән) азат ителгән яки контрактны (башка хокукый мөнәсәбәтләрне) үтәүне тәмамлаган һәм билгеләнгән тәртиптә эшсез яки эш эзләүче дип танылган очракта, махсус хәрби операциядә катнашучылар – әлеге затларга индивидуаль эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыру буенча актив гамәлләр кылуга стимул бирү максатларында;

в) I яки II төркем инвалид дип танылган һәм хәрби хезмәттән (хезмәттән, эштән) азат ителгән яки контрактны (башка хокукый мөнәсәбәтләрне) үтәүне тәмамлаган

махсус хәрби операциядә катнашучыларны сайлап алуы буенча – махсус хәрби операциядә катнашучы үзенең социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү хокукыннан баш тарту шарты белән (махсус хәрби операциядә катнашучылар эшкә яраксыз дип танылган очраклардан тыш) аларның эшсез яки эш эзләүче дип билгеләнгән тәртиптә танылган хатыны (ире) – әлеге затларга индивидуаль эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыру буенча актив гамәлләр кылуга стимул бирү максатларында.

Махсус хәрби операциядә катнашучының социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәменнән файдалану хокукыннан баш тартуы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 16 ноябрендәге 1931 нче карары белән расланган «Ватанны саклаучылар» махсус хәрби операциядә катнашучыларга ярдәм күрсәтү буенча дәүләт фонды («Ватанны саклаучылар» махсус хәрби операциядә катнашучыларга ярдәм күрсәтү буенча дәүләт фонды филиалы) тарафыннан социаль контракт төзүгә тәкъдимнамәләр бирү кагыйдәләренә 2 нче кушымтада бирелгән форма буенча гариза күчермәсе белән раслана.

Әлеге пунктчаның икенче абзацында күрсәтелгән гаризаның күчермәсе территориаль социаль яклау органында саклана. Махсус хәрби операциядә катнашучының социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәменнән файдалану хокукыннан баш тартуы турында мәгълүматлар әлеге Нигезләмәнең 24 пунктындагы «х» һәм «ч» пунктларын куллану максатларында махсус хәрби операциядә катнашучыга да һәм махсус хәрби операциядә катнашучы тарафыннан социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәменнән файдалану хокукыннан баш тартуы гамәлгә ашырылган хатынына (иренә) да карата «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасына кертелә.

Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү социаль контрактсыз дәүләт социаль ярдәме күрсәтүне туктатуга яки дәүләт социаль ярдәме билгеләүдән баш тартуга китерми.»;

түбәндәге эчтәлекле $9^1$ пункт өстәргә:

«$9^1$. 178-ФЗ номерлы Федераль законның $8^1$ статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән гражданнарның социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәменә хокукы 178-ФЗ номерлы Федераль законның $8^2$ статьясында күрсәтелгән түбәндәге үзенчәлекләрне исәпкә алып барлыкка килә:

44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гаиләнең уртача керемен (ялгыз яшәүче гражданның керемен) бәяләмичә;

әлеге Нигезләмәнең 10 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән чараны гамәлгә ашыру максатларында;

«Ватанны саклаучылар» махсус хәрби операциядә катнашучыларга ярдәм күрсәтү буенча дәүләт фонды («Ватанны саклаучылар» махсус хәрби операциядә катнашучыларга ярдәм күрсәтү буенча дәүләт фонды филиалы) тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 16 ноябрендәге 1931 номерлы карары белән расланган тәртиптә һәм форма буенча бирелә торган социаль контракт төзүгә тәкъдимнамәләр булганда;

178-ФЗ номерлы Федераль законның $8^1$ статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән гражданнар белән социаль контракт, аларга индивидуаль эшмәкәр буларак индивидуаль эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыру буенча актив гамәлләр кылуга стимул бирү максатларында, бер тапкыр төзелә.

«Ватанны саклаучылар» махсус хәрби операциядә катнашучыларга ярдәм күрсәтү буенча дәүләт фонды («Ватанны саклаучылар» махсус хәрби операциядә катнашучыларга ярдәм күрсәтү буенча дәүләт фонды филиалы) тарафыннан социаль контракт төзү өчен тәкъдимнамәләр бирү кагыйдәләре Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 16 ноябрендәге 1931 номерлы карары белән расланды.»;

10 пунктта:

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«г) граждан тарафыннан авыр тормыш хәлен җиңүгә юнәлдерелгән башка чараларны гамәлгә ашыру (Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы белән раслана торган бертип авыр тормыш хәлләре (гражданның тормыш эшчәнлеге шартларын начарайта, шул исәптән гражданның (граждан гаиләсенең) керем дәрәҗәсенә тискәре йогынты ясый торган һәм зыяннарын мөстәкыйль җмөеп чыга алмый торган, еш очрый торган хәлләр) һәм социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтелә торган гаиләләр (ялгыз яшәүче гражданнар) категорияләре исемлеге). Башка чаралар дигәндә әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы «г» пунктчасы нигезендә гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алуга агымдагы ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатларында 178-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясындагы 1 өлешенең икенче абзацында каралган дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә юнәлдерелгән чаралар аңлашыла.»;

алтынчы абзацта «Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

11 пунктта «программасына» сүзләрен «программасына адреслы якын килүне гамәлгә ашыру максаты белән» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле $11^1$ пункт өстәргә:

«$11^1$. Социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәгенең гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм үзәге (халыкка социаль хезмәт күрсәтү үзәге структурасындагы гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм бүлеге) (ала таба – үзәк (бүлек)) белгече тарафыннан социаль адаптация программасы төзелгәндә Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы белән формасы раслана торган, гариза бирүче белән әңгәмә анкетасына (алга таба – анкета) алынган нәтиҗәләре буенча белешмәләр кертелә торган әңгәмә үткәрелә.

Анкета алу нәтиҗәләре буенча үзәк (бүлек) тарафыннан, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү буенча методик тәкъдимнамәләрне раслау турында» 2024 елның 29 мартындагы 159 номерлы боерыгы белән расланган социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү буенча методик тәкъдимнамәләрне исәпкә алып, гражданны профайлинглау (типлаштыру) уздырыла.»;

12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Территориаль социаль яклау органы һәм үзәк (бүлек) тарафыннан социаль контракт, социаль адаптация программасы һәм аңа теркәлә торган материаллар, шулай ук гариза бирүче тарафыннан әзерләнгән бизнес-план (чыгымнар сметасы) социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия (алга таба – ведомствоара комиссия) утырышында социаль контракт төзегәнгә кадәр карала.

Ведомствоара комиссияләр Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә төзелә; аларның составларына социаль контракт төзүне хуплау (хупламау) турында килештерелгән фикерне, социаль адаптация программасын һәм аңа теркәлә торган материалларны, шулай ук гариза бирүче әзерләгән бизнес-планны (чыгымнар сметасын) яисә әлеге документларны эшләп бетерү кирәклеге турында килештерелгән фикерне әзерләү максатларында Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының башкарма комитетлары вәкилләре, шул исәптән икътисад бүлекләре, опека һәм попечительлек органнары, авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләре, халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары, территориаль социаль яклау органнары, җирле үзидарә органнары, башка органнар һәм оешмалар вәкилләре керә.

Ведомствоара комиссия үз эшчәнлеген әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтада китерелгән Бертип нигезләмә буенча Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) башкарма комитеты тарафыннан расланган Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия турындагы нигезләмәгә таянып гамәлгә ашыра.

Ведомствоара комиссия тапшырылган документларга бәя бирә, кирәк булганда, социаль адаптация һәм (яисә) бизнес-план программасын эшләп бетерү буенча тәкъдимнәр һәм тәкъдимнамәләр бирә, социаль контракт төзү мөмкинлеге (мөмкин булмавы) турында бәяләмә әзерли.

Ведомствоара комиссия әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымтада каралган форма һәм критерийлар буенча бизнес-планны (алга таба – бәяләү кәгазе) карый һәм бәяли. Ведомствоара комиссия әгъзалары тарафыннан бәяләү кәгазе нигезендә һәр критерий бәяләнә.

Һәр критерий буенча ведомствоара комиссия әгъзасы комментарий бирә. Бәяләү нәтиҗәләре буенча ведомствоара комиссия рәисе бизнес-планга гомуми комментарий бирә, анда бизнес-планны хуплау һәм (яки) эшкәртү буенча тәкъдимнәр, бизнес-планны хупламауның нигезле сәбәпләре чагылдырыла. Ведомствоара комиссия рәисе булмаганда, гомуми комментарийны ведомствоара комиссия рәисе урынбасары бирә.

Бизнес-планны бәяләү нәтиҗәләре бәяләү кәгазе нигезендә башкарыла һәм ведомствоара комиссия утырышы беркетмәсендә теркәлә.

Ведомствоара комиссия тарафыннан социаль контрактны, социаль адаптация программасын һәм аңа теркәлә торган материалларны, шулай ук гариза бирүче әзерләгән бизнес-планны (чыгымнар сметасын) эшләп бетерү кирәклеге турында килештерелгән фикер эшләнгән очракта, мондый документлар үзәк (бүлек) тарафыннан, гариза бирүче белән берлектә, эшләп бетерелә һәм әлеге килештерелгән фикер тапшырылган көннән алып биш эш көненә кадәр ведомствоара комиссиягә кабат карауга кертелә.

Ведомствоара комиссиянең вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

ведомствоара комиссия утырышында социаль контрактны, социаль адаптация программасын һәм аңа теркәлә торган материалларны, шулай ук гариза бирүче әзерләгән бизнес-планны (чыгымнар сметасын) карау;

территориаль социаль яклау органына социаль контракт, социаль адаптация программасы буенча, шул исәптән әлеге Нигезләмәнең 10 пунктында күрсәтелгән чаралар составы буенча, һәм (яисә) аңа теркәлә торган материаллар, шулай ук гариза бирүче әзерләгән бизнес-план (чыгымнар сметасы) буенча искәрмәләр кертелә;

әлеге пунктның дүртенче абзацы нигезендә эшләнеп беткән социаль контрактны, социаль адаптация программасын һәм аңа теркәлә торган материалларны, шулай ук гариза бирүче әзерләгән бизнес-планны (чыгымнар сметасын) кабат карап тикшерү;

әлеге пунктның икенче абзацы буенча социаль контракт төзүне хуплау (хупламау), социаль адаптация программасын һәм аңа теркәлә торган материалларны, шулай ук гариза бирүче әзерләгән бизнес-планны (чыгымнар сметасын) яисә әлеге документларны эшләп бетерү кирәклеге турында килештерелгән фикерне әзерләү.

Ведомствоара комиссия утырыш көнендә көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләрне карап тикшерә һәм түбәндәге карарны кабул итә:

социаль адаптация программасын һәм (яисә) бизнес-планны раслау турында карар кабул итә һәм гариза бирүче белән социаль контракт төзүне киңәш итә;

социаль адаптация программасы проектына һәм бизнес-планга үзгәрешләр кертүне (конкрет тәкъдимнәрне күрсәтеп) тәкъдим итү турында;

сайланган эшчәнлек төренең икътисадый нәтиҗәле булмау сәбәпле, социаль адаптация программасын гамәлгә ашыруның һәм гариза бирүче белән социаль контрактны гамәлгә ашыруның максатка ярашсызлыгы турында (мондый карарны кабул итү өчен мотивлаштырылган нигезләмә белән).

Ведомствоара комиссия социаль контрактны, социаль адаптация программасын һәм аңа теркәлә торган материалларны, шулай ук әлеге Нигезләмәдә каралган бизнес-планны (чыгымнар сметасын) хупламау турында карар кабул итәргә хокуклы.

Әлеге пунктның беренче абзацында каралган документларны территориаль социаль яклау органына тапшырган көннән алып биш эш көне үткәнгә кадәр ведомствоара комиссия утырышы уздырыла, аның нәтиҗәләре буенча комиссия утырышында рәислек иткән зат һәм ведомствоара комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана торган беркетмә рәсмиләштерелә һәм территориаль социаль яклау органына җибәрелә.

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы белән расланган формалар буенча социаль контракт төзү ведомствоара комиссия тарафыннан гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) социаль адаптация программасы һәм бизнес-план (чыгымнар сметасы) расланганнан соң гамәлгә ашырыла.

13 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. 178-ФЗ номерлы Федераль законның $8^1$ статьясындагы 1 өлешенең 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән гражданнар өчен социаль адаптация программасы билгеләү турында гариза теркәлгән көннән алып биш эш көне эчендә социаль контрактны алып барачак үзәк (бүлек) белгече тарафыннан, гариза бирүче һәм, кирәк булганда, түбәндәге органнар һәм оешмалар белән берлектә, аны төзү өчен кирәкле өстәмә бирелгән документларны, шулай ук әлеге Нигезләмәнең $11^1$ пунктында каралган анкетаны исәпкә алып эшләнә:»;

15 пунктның «б» пунктчасындагы икенче абзацына «төп чараларны» сүзләреннән соң «(автотранспорт (мототранспорт) чараларыннан, азсыешлы суднолардан, үзйөрешле машиналардан тыш)» сүзләрен өстәргә;

16 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Нигезләмәнең 10 пунктындагы «б» һәм «в» пунктчаларында күрсәтелгән чаралар буенча түләүләр халыкны социаль яклау органы тарафыннан индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәве булуы расланганнан соң (178-ФЗ номерлы

Федераль законның $8^1$ статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән гражданнар өчен) яки һөнәри керемгә салым түләүче буларак салым органында исәпкә куелганнан соң (178-ФЗ номерлы Федераль законның $8^1$ статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән гражданнар өчен) башкарыла.»

түбәндәге эчтәлекле $18^1$ пункт өстәргә:

«$18^1$. Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтелүче социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәм күрсәтүне туктату максатларында халыкны социаль яклау буенча территориаль органга Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 16 ноябрендәге 1931 номерлы карары белән расланган «Дәүләт социаль ярдәме турында» Федераль закон белән билгеләнмәгән өлештә Россия Федерациясе субъектлары тарафыннан федераль бюджеттан финанслашу шартларында социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү кагыйдәләренә 2 нче кушымтада бирелгән форма буенча дәүләт социаль ярдәме күрсәтүне туктату турындагы гариза белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Туктату турында гариза әлеге Нигезләмәнең 24 пункты буенча социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтелүче тарафыннан кире алынырга мөмкин.»;

19 һәм 20 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19. Әгәр билгеләү турында гариза дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр бердәм порталыннан яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталыннан файдаланып бирелгән булса, гариза бирүче территориаль социаль яклау органыннан аңа кирәкле документлар (белешмәләр) исемлегеннән гыйбарәт хәбәрнамә җибәрелгән көннән алып 10 эш көне эчендә исемлек нигезендә җитеп бетмәгән документларны (белешмәләрне) (килеп туган конкрет тормыш ситуациясенә карап) тапшыра.

Мондый очракта территориаль социаль яклау органы тарафыннан, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә, шул исәптән ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын файдаланып, органнардан һәм (яки) оешмалардан документлар (белешмәләр) алынган көннән алып бер эш көненнән дә соңга калмыйча, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр бердәм порталы яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталы аша гариза бирүчегә әлеге пунктның беренче абзацында каралган срок эчендә гариза бирүче тапшырырга тиеш кирәкле документлар (белешмәләр) исемлегеннән торган хәбәрнамә җибәрелә.

20. Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме билгеләү өчен шәхси мөрәҗәгать ителгәндә яки дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша мөрәҗәгать ителгәндә гариза бирүче тарафыннан документлар (белешмәләр) тулы булмаган комплектта тапшырылмаган булса, гариза бирүче территориаль социаль яклау органы тарафыннан аңа кирәкле документлар (белешмәләр) исемлегеннән гыйбарәт хәбәрнамә җибәрелгән көннән алып 10 эш көне эчендә исемлек нигезендә (килеп туган конкрет тормыш ситуациясенә карап) җитеп бетмәгән документларны (белешмәләрне) тапшыра.

Мондый очракта территориаль социаль яклау органы тарафыннан, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә, шул исәптән ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын файдаланып, органнардан һәм (яки) оешмалардан документлар (белешмәләр) алынган көннән алып бер эш көненнән дә

соңга калмыйча, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр бердәм порталы яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталы аша яки гаризада күрсәтелгән ысул белән гариза бирүчегә әлеге пунктның беренче абзацында каралган срок эчендә гариза бирүче тапшырырга тиеш кирәкле документлар (белешмәләр) исемлегеннән торган хәбәрнамә җибәрелә.»;

23 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«23. Гариза бирүче социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәм билгеләү яки туктату турында карар кабул ителгәнгә кадәр тапшырылган билгеләү турында гаризаны, шулай ук туктату турында гаризаны дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр бердәм порталыннан файдаланып яки территориаль социаль яклау органына, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 16 ноябрендәге 1931 номерлы карары белән расланган «Дәүләт социаль ярдәме турында» Федераль закон белән билгеләнмәгән өлештә Россия Федерациясе субъектлары тарафыннан федераль бюджеттан финанслашу шартларында социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү кагыйдәләренә 2 нче кушымтада бирелгән форма буенча элек тапшырылган гаризаны алу турында гариза белән мөрәҗәгать итеп кире алырга хокуклы.»;

түбәндәге эчтәлекле $23^1$ пункт өстәргә:

«$23^1$. Әгәр билгеләү турында гариза дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр бердәм порталыннан яки Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан файдаланып бирелгән булса, социаль контракт һәм аңа теркәлә торган социаль адаптация программасы гариза бирүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле булмаган электрон имза белән имзаланырга мөмкин; аның тикшерү ачкычы сертификаты Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә электрон формада дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик үзара бәйләнешен тәэмин итә торган инфраструктурада булдырыла һәм кулланыла.

Мондый очракта территориаль социаль яклау органы ягыннан социаль контрактка һәм аңа теркәлә торган социаль адаптация программасына «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасында яки органдагы һәм (яки) оешмадагы 178-ФЗ номерлы Федераль законның $6^{12}$ статьясындагы 6 өлешендә билгеләнгән таләпләргә туры килә торган мәгълүмат системасында көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалана.»;

24 пунктта:

«б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) билгеләү турында гаризада һәм (яки) документларда (белешмәләрдә), шул исәптән әлеге Нигезләмәнең 30 пункты нигезендә эшләп бетерелгән билгеләү турында гаризада һәм (яки) документларда (белешмәләрдә) дөрес булмаган һәм (яки) тулы булмаган мәгълүмат булу;»;

түбәндәге эчтәлекле «$в^1$» пунктчасын өстәргә:

«$в^1$) гариза бирүче тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 30 пунктында билгеләнгән сроклар эчендә территориаль социаль яклау органына эшләп бетерелгән билгеләү турында гариза һәм (яки) социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен билгеләү өчен кирәкле документлар (белешмәләр) тапшырылмау;»;

«и» пунктчасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«и) гариза бирүченең социаль контракт һәм социаль адаптация программасын имзалаудан баш тартуы яки социаль контракт һәм социаль адаптация программасын имзалау өчен килмәве, шулай ук дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр бердәм порталы яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталы аша имзалау өчен җибәрелгән очракта территориаль социаль яклау органы күрсәткән срок эчендә социаль контракт һәм социаль адаптация программасын имзаламавы;»;

«о» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«о) граждан индивидуаль эшмәкәр буларак теркәлгән (теркәлә) яки граждан Татарстан Республикасыннан читтә әлеге Нигезләмәнең 10 пунктындагы «б» һәм «в» пунктчаларында күрсәтелгән чаралар буенча әлеге Нигезләмәнең 53 пункты нигезендә үз эшчәнлеген һөнәри керемгә салым түләүче сыйфатында гамәлгә ашыра (гамәлгә ашырырга планлаштыра);»;

түбәндәге эчтәлекле у» – «ч» пунктчаларын өстәргә:

«у) гражданнар әлеге Нигезләмәнең 9 пунктындагы «б» һәм «в» пунктчалары буенча социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтелүгә хокук барлыкка килү нигезендә шундый ук ярдәм күрсәтелү өчен мөрәҗәгать иткән очракта, 178-ФЗ номерлы Федераль законның $8^1$ статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән гражданнарның әлеге Нигезләмәнең 10 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән чара буенча тәмамланган (гамәлдә булган) социаль контракты булу;

ф) әлеге Нигезләмәнең 10 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән чараны гамәлгә ашыру максатларында бизнес-планда күрсәтелгән эшчәнлек юнәлеше өстенлекле эшчәнлек юнәлешенә туры килмәве, аларның исемлеге әлеге Нигезләмәгә 3 нче кушымтада китерелә;

х) әлеге Нигезләмәнең 10 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән чараны гамәлгә ашыру максатларында әлеге Нигезләмәнең 9 пунктындагы «в» пунктчасы буенча социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү хокукыннан элегрәк баш тарткан граждан тарафыннан билгеләү турында гариза тапшыру;

ц) 178-ФЗ номерлы Федераль законның $8^1$ статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән граждан тарафыннан «Ватанны саклаучылар» махсус хәрби операциясендә катнашучыларга ярдәм итүнең дәүләт фонды («Ватанны саклаучылар» махсус хәрби операциясендә катнашучыларга ярдәм итүнең дәүләт фонды филиалы) тарафыннан бирелә торган социаль контрактны төзүгә тәкъдимнамәләр тапшырылмау;

ч) әлеге Нигезләмәнең 10 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән чараны гамәлгә ашыру максатларында әлеге Нигезләмәнең 9 пунктындагы «в» пунктчасы буенча социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү хокукыннан элегрәк баш тарткан гражданның яңа хатыны (ире) тарафыннан элеккеге хатыны (ире) файдасына билгеләү турында гариза тапшыру.»;

25 пунктта:

«а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) тәмамланган социаль контракт булу;»;

«в» пунктчасына «хезмәт эшчәнлеген» сүзләреннән соң «иң күбе бер айга» сүзләрен өстәргә;

«з» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«з) социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтелүче тарафыннан социаль адаптация программасы чаралары Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы белән расланган нигезле сәбәпләр исемлегенә кермәгән сәбәпләр буенча үтәлмәү (үз вакытында үтәлмәү);»;

26 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«26. Социаль контракты буенча дәүләт социаль ярдәме күрсәтелүче тарафыннан социаль адаптация программасы чаралары үтәлмәгән очракта нигезле сәбәпләр исемлеге Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы белән раслана.»;

30 пунктның беренче абзацында «мондый гаризаларны» сүзләрен «мондый гаризаны» сүзләренә, «кире кайтарырга» сүзләрен «бер тапкыр кире кайтарырга» сүзләренә алмаштырырга;

31 пунктта:

«и» пунктчасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«и) социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтелүче тарафыннан социаль адаптация программасында каралган чаралар Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы белән раслана торган нигезле сәбәпләр исемлегенә кермәгән сәбәпләр буенча үтәлмәү (үз вакытында үтәлмәү);»;

түбәндәге эчтәлекле «и$^1$» пунктчасын өстәргә:

«и$^1$) социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтелүче тарафыннан социаль адаптация программасында каралган чаралар Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы белән исемлеге раслана торган нигезле сәбәпләр буенча үтәлмәү (әлеге Нигезләмәнең 32$^1$ пунктында билгеләнгән очрактан тыш);»;

«м» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«м) территориаль социаль яклау органы гражданнан туктату турында гариза алу;»;

түбәндәге эчтәлекле «н» пунктчасын өстәргә:

«н) гариза бирүче социаль контрактның өстәмә килешүенә кул куядан баш тарту яки ул социаль контрактның өстәмә килешүенә имза куюга килмәү, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 32$^1$ пунктындагы икенче абзацында һәм 32$^2$ пунктындагы икенче абзацында каралган очракларда аны дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр бердәм порталы яки Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша имза куюга җибәргәндә территориаль социаль яклау органы тарафыннан күрсәтелгән срок эчендә өстәмә килешүгә имза куймау.»;

түбәндәге эчтәлекле 32$^1$ – 32$^3$ пунктлар өстәргә:

«32$^1$. Әлеге Нигезләмәнең 31 пунктындагы «и$^1$» пунктчасында күрсәтелгән шарт барлыкка килүне тикшергәннән соң, территориаль социаль яклау органы, социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтелүче белән килештереп, социаль контрактка һәм (яки) социаль адаптация программасына, шулай ук бизнес-планга (чыгымнар сметасына) үзгәрешләр кертергә һәм (яки) социаль контрактның гамәлдә булу срогын иң күбе гамәлдәге социаль контракт срогының яртысына озайтырга хокуклы.

Социаль контрактның гамәлдә булу вакытын озайту һәм (яки) социаль

контрактка һәм (яки) социаль адаптация программасына, шулай ук бизнес-планга (чыгымнар сметасына) үзгәрешләр кертү максатларында территориаль социаль яклау органы социаль контрактка өстәмә килешү төзи.

Социаль контрактка һәм (яки) социаль адаптация программасына һәм (яки) социаль контрактның гамәлдә булу срогын озайтуга үзгәрешләр кертелгән очракта, территориаль социаль яклау органы тарафыннан социаль контрактка һәм (яки) социаль адаптация программасына, шулай ук бизнес-планга (чыгымнар сметасына) үзгәрешләр кертелгән һәм (яки) социаль контрактның гамәлдә булу срогын озайту көненнән алып өч эш көне эчендә социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтелүчегә гаризада күрсәтелгән ысул белән, шул исәптән дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр бердәм порталын файдаланып, тиешле хәбәрнамә җибәрелә.

32$^{2}$. Әгәр социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтелүче индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвеннән төшерелгән яисә индивидуаль эшмәкәр булмаган граждан һөнәри керемгә салым түләүче буларак салым органыннан исәптән төшерелгән көннән алып 10 эш көне эчендә яңадан индивидуаль эшмәкәр буларак теркәлсә яки һөнәри керемгә салым түләүче буларак салым органына исәпкә басса, әлеге Нигезләмәнең 31 пунктындагы «к$^{1}$» пунктчасында күрсәтелгән шарт буенча туктату турында карар территориаль социаль яклау органы тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 31 пункты нигезендә кабул ителми.

Мондый очракта территориаль социаль яклау органы тарафыннан, социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтелүче белән килештереп, социаль адаптация программасына үзгәреш кертелә һәм социаль контрактка өстәмә килешү төзелә.

32$^{3}$. Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме туктатылу турында карар кабул итү һәм әлеге Нигезләмәнең 10 пунктындагы «а» – «в» пунктчаларында күрсәтелгән чаралар буенча социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме буларак алынган акчаны кире кайтару кирәклеген билгеләү максатларында әлеге Нигезләмәнең 31 пунктындагы «м» пунктчасында күрсәтелгән шарт буенча территориаль социаль яклау органы тарафыннан, әгәр социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтелүче Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы белән раслана торган исемлектәге социаль адаптация программасы чаралары үтәлмәгән булса, нигезле сәбәпләр булуны тикшерә.»;

34 пунктта:

беренче абзацта «Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясында» сүзләрен «178-ФЗ номерлы Федераль законның 8$^{1}$ статьясындагы 1 өлешенең 1 һәм 2 пунктларында» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «Кече һәм урта эшмәкәрлек һәм индивидуаль эшмәкәрлек инициативасына ярдәм» илкүләм проектын гамәлгә ашыру кысаларында» сүзләрен төшереп калдырырга;

алтынчы абзацта «178-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясында» сүзләрен «178-ФЗ номерлы Федераль законның 8$^{1}$ статьясындагы 1 өлешенең 1 һәм 2 пунктларында» сүзләренә алмаштырырга;

36 пунктта «Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясында» сүзләрен «178-ФЗ номерлы Федераль законның 8$^{1}$ статьясындагы 1 өлешенең 1 һәм 2 пунктларында» сүзләренә

алмаштырырга;

39 пунктта:

«а» пунктчасының өченче абзацында «чыкканнан» сүзен «тәмамланганнан» сүзенә алмаштырырга;

«б» пунктчасында:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алу (178-ФЗ номерлы Федераль законның $8^1$ статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән гражданнар өчен) яки һөнәри керемгә салым түләүче буларак салым органында исәпкә кую (178-ФЗ номерлы Федераль законның $8^1$ статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән гражданнар өчен) (социаль контракт төзү датасына мондый теркәлү яки исәпкә куелу булмаган очракта);»;

өченче абзацта:

«чыкканнан» сүзен «тәмамланганнан» сүзенә алмаштырырга;

татар текстында «арттыру (чыганак булдыру)» сүзләреннән соң «– 178-ФЗ номерлы Федераль законның $8^1$ статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән гражданнар өчен» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«социаль контрактның гамәлдә булу срогы тәмамланганнан соң эшмәкәрлек эшчәнлегеннән керемне арттыру (чыганак булдыру) – әлеге Нигезләмәнең 9 пунктындагы «б» һәм «в» пунктчаларында күрсәтелгән гражданнар өчен;»;

«в» пунктчасының өченче абзацында «чыкканнан» сүзен «тәмамланганнан» сүзенә алмаштырырга;

«г» пунктчасының беренче абзацында «чыкканнан» сүзен «тәмамланганнан» сүзенә алмаштырырга;

41 пунктта татар текстында «бәяләү турында яки» сүзләреннән соң «Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан исемлеге раслана торган нигезләр буенча» сүзләрен өстәргә;

42 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«42. Социаль контрактның гамәлдә булу срогы тәмамланган айдан соң бишенче ай эчендә территориаль социаль яклау органы социаль контрактны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү турында хисап әзерли, ул түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

билгеләү турында гариза биргәндә исәпләнгән уртача керем белән чагыштырып, социаль контрактның гамәлдә булу срогы тәмамланган айдан соң килә торган өч ай өчен гаиләнең уртача кереме яки ялгыз яшәүче гражданның кереме турында белешмәләр – Федераль законның 178-ФЗ $8^1$ статьясы 1 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән гражданнар өчен;

социаль контрактның гамәлдә булу срогы тәмамланган айдан соң килә торган өч ай өчен эшмәкәрлек эшчәнлегеннән керем турында белешмә – 178-ФЗ номерлы Федераль законның $8^1$ статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән гражданнар өчен;

социаль контрактның гамәлдә булу срогы тәмамланганнан соң гражданның (гражданның гаиләсенең) тормыш шартларын бәяләү.

Җыелма хисап территориаль социаль яклау органы тарафыннан ай саен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау

министрлыгына тапшырыла.»;

43 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«43. Территориаль социаль яклау органы тарафыннан социаль контрактның гамәлдә булу срогы тәмамланган көннән алып гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) яшәү шартларына мониторинг үткәрә.

Гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) яшәү шартларын мониторинглау барышында алынган нәтиҗәләр буенча территориаль социаль яклау органы граждан (178-ФЗ номерлы Федераль законның $8^1$ статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән гражданнардан тыш) белән яңа социаль контракт төзүнең яки аңа (аның гаиләсенә) башка социаль ярдәм чаралары яки хезмәтләр күрсәтү максатка ярашлылыгы турында карар кабул итә.

Гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) яшәү шартларына мониторинг үткәрелә, шул исәптән:

а) әлеге Нигезләмәнең 10 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән чара буенча:

ай саен 12 ай дәвамында гамәлдәге хезмәт шартнамәсе (хезмәт контракты) булу факты тикшерелә;

квартал саен 12 ай дәвамында социаль контрактның гамәлдә булу срогы тәмамланган көннән алып 4, 5, 6 нчы айлар, 7, 8, 9 нчы айлар һәм 10, 11, 12 нче айлар өчен гражданның  хезмәт эшчәнлегеннән уртача кереме исәпләнә;

квартал саен 12 ай дәвамында социаль контрактның гамәлдә булу срогы тәмамланган көннән алып 4, 5, 6 нчы айлар, 7, 8, 9 нчы айлар һәм 10, 11, 12 нче айлар өчен гаиләнең җан башына уртача кереме (ялгыз яшәүче гражданның кереме) исәпләнә;

б) әлеге Нигезләмәнең 1.7 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән чара буенча:

ай саен 12 ай дәвамында индивидуаль эшмәкәр буларак гражданны дәүләт теркәвенә алу (178-ФЗ номерлы Федераль законның $8^1$ статьясы 1 өлешендә күрсәтелгән гражданнар өчен) яки һөнәри керемгә салым түләүче буларак салым органында исәпкә кую факты (178-ФЗ номерлы Федераль законның $8^1$ статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән гражданнар өчен) тикшерелә;

квартал саен 12 ай дәвамында социаль контрактның гамәлдә булу срогы тәмамланган көннән алып 4, 5, 6 нчы айлар, 7, 8, 9 нчы айлар һәм 10, 11, 12 нче айлар өчен гражданның эшкуар эшчәнлегеннән уртача кереме исәпләнә;

квартал саен 12 ай дәвамында социаль контрактның гамәлдә булу срогы тәмамланган көннән алып 4, 5, 6 нчы айлар, 7, 8, 9 нчы айлар һәм 10, 11, 12 нче айлар өчен гаиләнең җан башына уртача кереме исәпләнә – 178-ФЗ номерлы Федераль законның $8^1$ статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән гражданнар өчен;

в) әлеге Нигезләмәнең 1.7 пунктындагы «в» пунктчасында күрсәтелгән чара буенча:

ай саен 12 ай дәвамында гражданның салым органында һөнәри керемгә салым түләүче сыйфатында исәпкә куелу факты тикшерелә;

квартал саен 12 ай дәвамында социаль контрактның гамәлдә булу срогы тәмамланган көннән алып 4, 5, 6 нчы айлар, 7, 8, 9 нчы айлар һәм 10, 11, 12 нче айлар өчен гражданның әзхси ярдәмче хуҗалык алып барудан уртача кереме исәпләнә;

квартал саен 12 ай дәвамында социаль контрактның гамәлдә булу срогы тәмамланган көннән алып 4, 5, 6 нчы айлар, 7, 8, 9 нчы айлар һәм 10, 11, 12 нче айлар өчен гаиләнең җан башына уртача кереме (ялгыз яшәүче гражданның кереме) исәпләнә;

г) әлеге Нигезләмәнең 1.7 пунктындагы «г» пунктчасында күрсәтелгән чара буенча:

квартал саен 12 ай дәвамында гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) матди-көнкүреш хәле начарлану факты тикшерелә;

квартал саен 12 ай дәвамында социаль контрактның гамәлдә булу срогы тәмамланган көннән алып 4, 5, 6 нчы айлар, 7, 8, 9 нчы айлар һәм 10, 11, 12 нче айлар өчен гаиләнең җан башына уртача кереме (ялгыз яшәүче гражданның кереме) исәпләнә;»;

45 пунктның «и» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«и) социаль контракт төзелгән датадан алып бер ай эчендә бирелә торган, дәүләт социаль ярдәме буларак алынган акчалата түләүне, әлеге Нигезләмәнең 31 пункты буенча социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме туктатылган очракта, әлеге Нигезләмәнең 61 пункты нигезендә (әлеге Нигезләмәнең 31 пунктындагы «а», «б», «и$^1$», «к$^1$» һәм «л» пунктчаларында күрсәтелгән очраклардан тыш) түләүне кире кайтару турында кирәклеге турында хәбәрнамә дәүләт социаль ярдәме күрсәтелүче тарафыннан алынган көннән 30 календарь көн эчендә тулы күләмдә кире кайтарырырга (социаль контракт Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы белән раслана торган исемлектәге сәбәпләр буенча туктату турында гариза буенча туктатылу шарты белән).»;

түбәндәге эчтәлекле 46$^1$ пункт өстәргә:

«46$^1$. Әлеге Нигезләмәнең 10 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән чара буенча 178-ФЗ номерлы Федераль законның 8$^1$ статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән гражданнарга социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү кысаларында кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмалар, шул исәптән «Мой бизнес» үзәкләре социаль контракт төзү, гамәлдә булу һәм әлеге Нигезләмәнең 43 пункты нигезендә үткәрелә торган мониторинг чорында дәүләт социаль ярдәме күрсәтелүчегә эшмәкәрлек эшчәнлеген алып бару мәсьәләләре буенча консультация һәм методология ярдәме күрсәтә.»;

47 пунктта:

«а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) индивидуаль эшмәкәр буларак теркәлергә (178-ФЗ номерлы Федераль законның 8$^1$ статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән гражданнар өчен) яки һөнәри керемгә салым түләүче буларак салым органында исәпкә басарга (178-ФЗ номерлы Федераль законның 8$^1$ статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән гражданнар өчен) (социаль контракт төзү датасына граждан индивидуаль эшмәкәр буларак теркәлмәү, һөнәри керемгә салым түләүче буларак салым органында исәптә тормау шарты белән);»;

«д» пунктчасында «төп чаралар» сүзләреннән соң «(автотранспорт (мото-транспорт) чараларыннан, азсыешлы суднолардан, үзйөрешле машиналардан тыш)» сүзләрен өстәргә;

«е» һәм «ж» пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«е) дәүләт социаль ярдәме буларак алынган акчаны, әлеге Нигезләмәнең 31 пункты буенча социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме туктатылган очракта, әлеге Нигезләмәнең 61 пункты нигезендә (әлеге Нигезләмәнең 31 пунктындагы «а», «б», «и$^1$», «к» пунктчаларында күрсәтелгән очраклардан тыш) түләүне кире кайтару турында кирәклеге турында хәбәрнамә дәүләт социаль ярдәме күрсәтелүче тарафыннан алынган көннән 30 календарь көн эчендә һәм тулы күләмдә кире кайтарырырга (социаль контракт Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы белән раслана торган исемлектәге нигезле сәбәпләр буенча туктату турында гариза буенча туктатылу шарты белән).»;

ж) социаль контрактның гамәлдә булу срогы чорында һәм социаль контрактның гамәлдә булу срогы тәмамланган көннән алып кимендә 12 ай дәвамында эшмәкәрлек эшчәнлеген (178-ФЗ номерлы Федераль законның 8$^1$ статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән гражданнар өчен), шул исәптән һөнәри керемгә салым түләүче буларак (178-ФЗ номерлы Федераль законның 8$^1$ статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән гражданнар өчен) гамәлгә ашырырга;»;

49 пунктның «ж» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ж) дәүләт социаль ярдәме буларак алынган акчаны, әлеге Нигезләмәнең 31 пункты буенча социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме туктатылган очракта, әлеге Нигезләмәнең 61 пункты нигезендә (әлеге Нигезләмәнең 31 пунктындагы «а», «б», «и$^1$», «к» һәм «м» пунктчаларында күрсәтелгән очраклардан тыш) түләүне кире кайтару турында кирәклеге турында хәбәрнамә дәүләт социаль ярдәме күрсәтелүче тарафыннан алынган көннән 30 календарь көннән соңга калмыйча һәм тулы күләмдә кире кайтарырырга (социаль контракт Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы белән раслана торган исемлектәге нигезле сәбәпләр буенча туктату турында гариза буенча туктатылу шарты белән);»;

52 һәм 53 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«52. Территориаль социаль яклау органы тарафыннан социаль контрактка һәм (яки) социаль адаптация программасына, шулай ук бизнес-планга (чыгымнар сметасына), социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтелүче белән килештереп, үзгәрешләр кертелергә мөмкин.

Әгәр социаль контрактка һәм (яки) социаль адаптация программасына, шулай ук бизнес-планга (чыгымнар сметасына) үзгәрешләр кертелсә, территориаль социаль яклау органы социаль адаптация программасына үзгәрешләр кертелгән көннән өч эш көне эчендә социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтелүчегә гаризада күрсәтелгән ысул белән, шул исәптән дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр бердәм порталы аша тиешле хәбәрнамә җибәрә.

53. Әлеге Нигезләмәнең 10 пунктындагы «б» һәм «в» пунктчаларында күрсәтелгән чаралар буенча социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме Татарстан Республикасында әлеге Нигезләмәнең 47 пунктындагы «а» пунктчасы һәм 49 пунктындагы «а» пунктчасы нигезендә граждан индивидуаль эшмәкәр буларак теркәлү (теркәләчәк) (178-ФЗ номерлы Федераль законның 8$^1$ статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән гражданнар өчен) яки граждан үз эшчәнлеген һөнәри керемгә салым түләүче буларак теркәлү (теркәләчәк) һәм гамәлгә ашыру (гамәлгә ашырырга планлаштыру) (178-ФЗ номерлы Федераль законның 8$^1$ статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән гражданнар өчен) шарты белән күрсәтелә.»;

55 пунктта:

беренче абзацта татар текстында «социаль контракт» сүзләренә кадәр «178-ФЗ номерлы Федераль законның $8^1$ статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән гражданнар арасыннан» сүзләрен өстәргә;

дүртенче абзацта татар текстында «социаль контракт» сүзләренә кадәр «178-ФЗ номерлы Федераль законның $8^1$ статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән гражданнар арасыннан» сүзләрен өстәргә;

56 пунктның беренче абзацында татар текстында «социаль контракт» сүзләренә кадәр «178-ФЗ номерлы Федераль законның $8^1$ статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән гражданнарга» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле $56^1$ пункт өстәргә:

«$56^1$. Татарстан Республикасында 178-ФЗ номерлы Федераль законның $8^1$ статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән гражданнарга социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү нәтиҗәлелеген бәяләү Россия Федерациясенең Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан «Гаилә» илкүләм проекты составына керә торган «Күпбалалы гаилә» федераль проекты белән расланган түбәндәге нәтиҗәлелек күрсәткечләре нигезендә гамәлгә ашырыла:

а) социаль контракт төзегән гражданнар саны (арта бара торган йомгак белән);

б) социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтелүче гражданнарның гомуми санында социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү нәтиҗәлелеген бәяләү чорында социаль контрактның гамәлдә булу срогы тәмамлануга эшмәкәрлек эшчәнлегеннән керем айга уртача Россия Федерациясе субъектында билгеләнгән халыкның җан башына яшәү минимумы күләменнән артып киткән социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтелүче гражданнар өлеше.»;

58 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«58. Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме билгеләү, күрсәтү, нәтиҗәлелеген бәяләү һәм аны мониторинглау барышы «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасын яки 178-ФЗ номерлы Федераль законның $6^{12}$ статьясындагы 6 өлешендә билгеләнгән таләпләргә туры килә торган органнарның һәм (яки) оешмаларның мәгълүмат системаларын файдаланып башкарыла. Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү кысаларында бирелә торган түләү эшләре, акча түләү һәм аны китереп бирү документлары, шулай ук социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме билгеләүдән баш тарту турында эшләр, «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасын яки 178-ФЗ номерлы Федераль законның $6^{12}$ статьясындагы 6 өлешендә билгеләнгән таләпләргә туры килә торган органнарның һәм (яки) оешмаларның мәгълүмат системаларын файдаланып, архив эше турында Россия Федерациясе законнары нигезендә электрон формада саклана.

Территориаль социаль яклау органы «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасына социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында мәгълүмат кертә. Территориаль социаль яклау органы тарафыннан «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасын файдаланганда социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында мәгълүмат автоматлаштырылган тәртиптә формалаштырыла.»;

61 пунктның беренче абзацында татар текстында «әлеге Нигезләмәнең»

сүзләреннән соң «45 пунктындагы «и» пунктчасы» сүзләрен өстәргә;

әлеге Нигезләмәгә 1 – 3 нче кушымталарны яңа редакциядә (карарга теркәләләр) бәян итәргә;

әлеге Нигезләмәгә 4 нче һәм 5 нче кушымталар үз көчен югалткан дип танырга.

2. Бу карарның гамәле 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү тәртибе турында нигезләмәгә 6 нчы кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2026 ел, 28 гыйнвар, 51 нче карары редакциясендә)

Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә бәйле мәсьәләләрне карап тикшерү буенча ведомствоара комиссия турында бертип нигезләмә

1. Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә бәйле мәсьәләләрне карап тикшерү буенча ведомствоара комиссия (алга таба – ведомствоара комиссия) авыр тормыш хәлендә калган гражданнар мөрәҗәгатьләрен һәрьяклап һәм объектив карап тикшерү, гражданның һәм (яки) аның гаиләсенең авыр тормыш хәленнән чыгу буенча килештерелгән чаралар эшләү өлешендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәме, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү турында» 2023 ел, 25 декабрь, 1682 нче карарын гамәлгә ашыру максатларында төзелә һәм күмәк орган булып тора.

2. Ведомствоара комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы хокукый актларына, муниципаль хокукый актларга, шулай ук әлеге Бертип нигезләмәгә таянып эш итә.

3. Ведомствоара комиссияне рәис җитәкли.

Ведомствоара комиссия составына социаль контракт төзүне хуплау (хупламау) турында килештерелгән фикерне, социаль адаптация программасын һәм аңа теркәлә торган материалларны, шулай ук гариза бирүче әзерләгән бизнес-планны (чыгымнар сметасын) яисә әлеге документларны эшләп бетерү кирәклеге турында килештерелгән фикерне әзерләү максатларында Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының башкарма комитетлары вәкилләре, шул исәптән икътисад бүлекләре, опека һәм попечительлек органнары, авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләре, халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары, территориаль социаль яклау органнары, җирле үзидарә органнары, башка органнар һәм оешмалар вәкилләре керә.

4. Ведомствоара комиссия социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү мәсьәләләрен социаль контракт төзегәнгә кадәр карап тикшерә, тапшырылган документларга бәя бирә, кирәк булганда социаль адаптация программасын һәм (яки) бизнес-планны эшләп бетерү буенча тәкъдимнәр һәм тәкъдимнамәләр кертә, социаль контракт төзү мөмкинлеге (мөмкин булмавы) турында бәяләмә әзерли.

5. Ведомствоара комиссиянең төп бурычлары түбәндәгеләр:

законнар нигезендә авыр тормыш хәлендә калган затларга адреслы социаль ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча федераль башкарма хакимият органнарының

Татарстан Республикасындагы территориаль органнары, республика башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр, муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан башка оешмалар хезмәттәшлеген тәэмин итү;

граждан тарафыннан кабул ителә торган йөкләмәләр нигезендә граждан һәм (яки) аның гаиләсен авыр тормыш хәленнән чыгару өчен шартлар тудыру.

6. Бурычларны хәл итү өчен ведомствоара комиссия түбәндәге хокукларга ия:

ведомствоара комиссия эшендә катнашу өчен федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасындагы территориаль органнары, республика башкарма хакимият органнарының территориаль органнарының вазыйфаи затларын һәм белгечләрен, шулай ук муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан оешмалар вәкилләрен җәлеп итәргә;

федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасындагы территориаль органнарыннан, республика башкарма хакимият органнарыннан һәм аларның территориаль органнарыннан, оешмалардан һәм вазыйфаи затлардан кирәкле материаллар һәм мәгълүматларны билгеләнгән тәртиптә соратырга һәм алырга;

ведомствоара комиссия утырышларына авыр тормыш хәлендә калган гражданнарны чакырырга, аларның аңлатмаларын тыңларга;

законнар һәм бюджет йөкләмәләре лимиты кысаларында социаль адаптация программасында үтәлеше беркетелә торган, гражданны һәм (яки) гаиләне авыр тормыш хәленнән чыгаруга юнәлдерелгән чаралар буенча фикер алышырга һәм аларны гражданнарга тәкъдим итәргә;

федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасындагы территориаль органнарына, республика башкарма хакимият органнарының территориаль органнарына, Татарстан Республикасының дәүләт учреждениеләренә һәм муниципаль учреждениеләргә, муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан башка оешмаларга үз вәкаләтләре чикләрендә гражданны һәм (яки) аның гаиләсен авыр тормыш хәленнән чыгару чараларын гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә;

законнар нигезендә социаль адаптация программасында беркетелгән шартларның һәм йөкләмәләрнең үтәлешен тикшерүне билгеләргә.

7. Межведомственная комиссия вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

ведомствоара комиссия утырышында социаль контрактны, социаль адаптация программасын һәм аңа теркәлә торган материалларны, шулай ук гариза бирүче әзерләгән бизнес-планны (чыгымнар сметасын) карау;

территориаль социаль яклау органына социаль контракт, социаль адаптация программасы буенча, шул исәптән анда күрсәтелгән чаралар составы буенча, һәм (яисә) аңа теркәлә торган материаллар, шулай ук гариза бирүче әзерләгән бизнес-план (чыгымнар сметасы) буенча искәрмәләр кертелә;

эшләп бетерелгән социаль контрактны, социаль адаптация программасын һәм аңа теркәлә торган материалларны, шулай ук гариза бирүче әзерләгән бизнес-планны (чыгымнар сметасын) яңадан карау;

социаль контракт төзүне хуплау (хупламау), социаль адаптация программасын һәм аңа теркәлә торган материалларны, шулай ук гариза бирүче әзерләгән бизнес-планны (чыгымнар сметасын) яисә әлеге документларны эшләп бетерү кирәклеге турында килештерелгән фикерне әзерләү.

8. Ведомствоара комиссия эшчәнлеге белән җитәкчелек итүне аның рәисе, ул

булмаганда ведомствоара комиссия рәисе урынбасары башкара.

9. Ведомствоара комиссия утырышлары ведомствоара комиссия рәисе тарафыннан расланган утырышлар графигы буенча үткәрелә.

10. Ведомствоара комиссия утырышлары, әгәр анда ведомствоара комиссия әгъзаларының билгеләнгән составыннан кимендә ярты әгъзасы катнашса, тулы хокуклы була.

11. Ведомствоара комиссиянең хокуклылыгын билгеләү өчен һәр утырыш алдыннан ведомствоара комиссия әгъзалары теркәлә.

12. Ведомствоара комиссия карарлары ведомствоара комиссия утырышында катнашучы әгъзалар санынннан гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, ведомствоара комиссия утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

Ведомствоара комиссия әгъзалары тавыш бирүне шәхсән башкара, үз вәкаләтләрен башка затларга тапшыру рөхсәт ителми.

13. Ведомствоара комиссия тапшырылган документларга бәя бирә, кирәк булганда, социаль адаптация һәм (яисә) бизнес-план программасын эшләп бетерү буенча тәкъдимнәр һәм тәкъдимнамәләр бирә, социаль контракт төзү мөмкинлеге (мөмкин булмавы) турында бәяләмә чыгара.

Ведомствоара комиссия бизнес-планны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәме, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү турында» 2023 ел, 25 декабрь, 1682 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәме, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәнең 2 нче кушымтасында каралган форма һәм критерийлар буенча карап тикшерүне һәм бәяләүне (алга таба – бәяләү кәгазе) гамәлгә ашыра.

Һәр критерий буенча ведомствоара комиссия әгъзасы комментарий бирә. Бәяләү нәтиҗәләре буенча ведомствоара комиссия рәисе бизнес-планга гомуми комментарий бирә, анда бизнес-планны хуплау һәм (яки) эшкәртү буенча тәкъдимнәр, бизнес-планны хупламауның нигезле сәбәпләре чагылдырыла. Ведомствоара комиссия рәисе булмаганда, гомуми комментарийны ведомствоара комиссия рәисе урынбасары бирә.

Бизнес-планны бәяләү нәтиҗәләре бәяләү кәгазе нигезендә башкарыла һәм ведомствоара комиссия утырышы беркетмәсендә теркәлә.

14. Ведомствоара комиссия утырыш көнендә көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләрне карап тикшерә һәм түбәндәге карарны кабул итә:

социаль адаптация программасын һәм (яисә) бизнес-планны раслау турында карар кабул итә һәм гариза бирүче белән социаль контракт төзүне киңәш итә;

социаль адаптация программасы проектына һәм бизнес-планга үзгәрешләр кертүне (конкрет тәкъдимнәрне күрсәтеп) тәкъдим итү турында;

сайланган эшчәнлек төренең икътисадый нәтиҗәле булмау сәбәпле, социаль адаптация программасын гамәлгә ашыруның һәм гариза бирүче белән социаль контрактны гамәлгә ашыруның максатка ярашсызлыгы турында (мондый карарны кабул итү өчен мотивлаштырылган нигезләмә белән).

Ведомствоара комиссия социаль контрактны, социаль адаптация программасын

һәм аңа теркәлә торган материалларны, шулай ук бизнес-планны (чыгымнар сметасын) хупламау турында карар кабул итәргә хокуклы.

15. Ведомствоара комиссия утырышы нәтиҗәләре буенча беркетмә рәсмиләштерелә, аңа комиссия утырышында рәислек итүче зат һәм ведомствоара комиссия әгъзалары тарафыннан имза куела.

Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү тәртибе турында нигезләмәгә
6 нчы кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2026 ел, 28 гыйнвар, 51 нче
карары редакциясендә)

Бәяләү кәгазе

____________________________________________________________
(граждан Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда) (тулысынча))

| Т/с | Критерий эчтәлеге | Комиссия әгъзасының фикерләре: искәрмәләр юк / нигезле искәрмәләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. Резюме | | |
| 1.1. | Белеме (төп, өстәмә) булу | |
| 1.2. | Сайланган юнәлеш буенча эш тәҗрибәсе, эшмәкәрлек эшчәнлеге булу | |
| 5 % | Оештыру-хокук формасын һәм салым системасын дөрес сайлау | |
| 5 % | Индивидуаль эшмәкәрлек эшчәнлеге (үзмәшгульлек) юнәлеше нигезендә проект буенча эшчәнлек төрләрен сайлау | |
| 5 % | Эшчәнлекне башкару өчен өстәмә документлар (лицензияләр, патентлар, сертификатлар, авторлык хокуклары, медицина кенәгәсе һ.б.) булу.<br>Өстәмә документлар алу кирәклеге (кирәк булмавы), аларны рәсмиләштерү тәртибе | |
| 5 % | Урнашу урыны, җитештерү урыннары | |
| 2. Бизнес тасвирламасы һәм маркетинг планы | | |
| 2.1. | Проект буенча бизнес тасвирламасы:<br>эш юнәлешләре;<br>бизнес өчен булган җиһазлар / товарлар / чимал / мөлкәт;<br>җитештерелә торган товарлар / эшләр / хезмәтләр тасвирламасы;<br>башка мәгълүмат (кирәк булганда) | |
| 2.2. | Максатчан аудиторияне билгеләү | |
| 2.3. | Конкурентлы мохитне, бизнесның конкурентлы позициясен анализлау | |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 2.4. | Товар (хезмәт) реализацияләү, сату базарларының эшкәртелү дәрәҗәсе | |
| 2.5. | Бизнесны алга җибәрү схемасының эшкәртелү дәрәҗәсе | |
| 3. Оештыру планы | | |
| 3.1. | Эш графигын, штат расписаниесен, персоналга карата таләпләрне билгеләү | |
| 4. Производство планы | | |
| 5 % | Бизнес өчен чыгымнарның нигезләнгән булуы, аларның Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү турында» 2023 ел, 25 декабрь, 1682 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәнең 47 пунктындагы «д» пунктчасына туры килүе | |
| 5. Финанс планы һәм проектның нәтиҗәлелек күрсәткечләре | | |
| 5 % | Проектның финанс тотрыклылыгы дәрәҗәсе:<br>финанс планының барлык бүлекләре дөрес тутырылган;<br>проектны гамәлгә ашыру өчен кирәкле барлык мөмкин чыгымнар исәпкә алынган;<br>проектны аклау өчен товар (хезмәт) сатудан табыш алу мөмкинлеге (табыш күләме);<br>финанс планының үтәлеше проектны гамәлгә ашырганда авырлыклар тудырмаячак;<br>проектның икътисадый нәтиҗәлелек күрсәткечләре дөрес исәпләнгән | |
| 6. Рисклар һәм аларны минимальләштерү чаралары тасвирламасы | | |
| 5 % | Мөмкин булган тышкы һәм эчке рискларның эшкәртелү дәрәҗәсе, аларны бетерү яки минимальләштерү буенча реаль чишелешләр | |

20___ ел, «__»____________ ________________________________

(имза) (имзаны таркатып язу)

_________________________

Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү тәртибе турында нигезләмәгә
6 нчы кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2026 ел, 28 гыйнвар, 51 нче
карары редакциясендә)

Индивидуаль эшмәкәрлек эшчәнлеген оештыру чараларын гамәлгә ашыру максатларында өстенлекле эшчәнлек (һөнәри керемгә салым түләүче буларак эшчәнлек) юнәлешләре исемлеге

1) IT һәм технологияләр;
2) финанслар һәм бизнес;
3) медицина һәм сәламәтлек саклау;
4) социаль өлкә
5) мәгариф.
6) консалтинг;
7) банк өлкәсе;
8) юриспруденция
9) маркетинг һәм реклама;
10) иҗат һәм дизайн;
11) логистика һәм транспорт;
12) төзелеш һәм инженерия;
13) җитештерү һәм эшкәртү;
14) туризм һәм кунакханә бизнесы;
15) җәмәгать туклануы;
16) авыл хуҗалыгы;
17) экология һәм табигатьне саклау;
18) матурлык өлкәсе;
19) мәдәният
20) сәүдә
21) персонал белән идарә итү;
22) торак-коммуналь хуҗалык
23) көнкүреш хезмәтләре, ремонтны кертеп;
24) автотранспорт чараларына техник хезмәт күрсәтү һәм аны ремонтлау;
25) нәшрият эше;
26) фото/видео хезмәтләр;
27) бәйрәмнәр һәм чаралар оештыру;
28) спорт һәм буш вакыт.

---